ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 18 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2013, № 10; 2015, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 83 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1. Юридик затларның яисә юридик зат төземичә генә эшкуарлык эшчәнлеген башкаручы гражданнарның түбәндәге объектларында (территорияләрендә, биналарында), тәүлекнең нинди вакыты булуга карамастан, балигъ булмаганнарга булу тыела:

1) сексуаль характердагы товарлар гына сату өчен каралган объектларда (территорияләрдә, биналарда);

2) сыра рестораннарында, шәраб барларында, сыра барларында, чәркәханәләрдә, алкоголь продукциясен генә сату өчен каралган башка урыннарда;

3) кальяннар кулланып хезмәт күрсәтелә торган биналарда, шулай ук тәмәке тарту, никотинлы продукция куллану яисә кальяннар куллану мөлкәт милекчесе яисә мөлкәт милекчесе вәкаләт биргән башка зат карары нигезендә рөхсәт ителә торган махсус бүленгән изоляцияләнгән урыннарда.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 23 декабрь
№ 135-ТРЗ